**СОВЕТ ЯМАШУРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422735, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Ямашурма, ул. Советская, 5

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯМАШИРМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422735, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Ямаширмә авылы, Совет ур., 5

Тел./факс: +7(84365) 777-02, e-mail: Yamash.Vsg@tatar.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**21 апрель 2021ел** **№27**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Ямаширмә авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә керми торган физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләрдәге яшел үсентеләрне кисү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясе Федераль законы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Ямаширмә авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Ямаширмә авыл җирлеге Советының 2021 елның 26 мартындагы 24 нче номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Ямаширмә авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә керми торган физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләрдәге яшел үсентеләрне кисү тәртибе турында Нигезләмә»гә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3.3. беренче пунктын 3.2 пунктының икенче абзацы итеп түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

«Рөхсәт бирү мөрәҗәгать итүченең салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына, авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш, бурычы булмаган очракта гамәлгә ашырыла.»;

2) 5.4. пунктта «территориясендә» сүзеннән алда «Ямаширмә авыл җирлеге» сүзләре белән тулыландырырга;

3) 6.4. пунктның бишенче абзацында, икенче җөмләдә «башкарма комитеты тарафыннан» сүзләре алдында «Ямаширмә авыл җирлеге» сүзләре белән тулыландырырга;

4) 6 бүлек. «Яшел утыртмаларны зарарлаган һәм (яисә) юкка чыгарган (кискән, җимергән) өчен җаваплылык» 7 бүлеккә алыштырырга;

5) 7 бүлек. «Әлеге Тәртипнең үтәлешенә контроль» 8 бүлеккә алыштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес

буенча һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Ф.К.Мухтаров